Мәсәлән, Авыр булды аннан аерылу,
Ни әйтсәң дә күңел – күңел шул!
*Авыр* булды миңа *аерылу*,
*Рәхәт* булыр кайткач *күрешү*. *(М. Җәлил)*

Кайвакыт антонимнардан ирония, юмор, сатира тудыру өчен кулланалар:

Икенче көн ни күрәм?!
Бер *елыйм* да бер *көләм*.
Урам тулы хатын-кыз,
Бар да ертык юбкадан. *(М. Җәлил)*

**Кулланылган әдәбият**

1. Әхтәмов М.Х. Башкорт теленең антонимнары//Башкортстан укытучысы. – 1972. – №4 (башкорт телендә).

2. Әхтәмов М.Х. башкорт теленең антонимнар сүзлеге. – Уфа:Башкортстан кит. нәшр.. 1987 (башкот телендә).

3. Усубалиев Б.Ш. Антонимы в киргизском языке: автореф. дисс. канд. филол. наук. – Фрунзе, 1982.

4. Ханбикова Ш.С. Антонимичные значения в слове (энантиосемия) // Лексика и стилистика татарского языка. – Казань, 1982.

5. Шукуров Р. Антонимы узбекского языка. – Ташкент: Фан, 1977.

## СҮЗЛЕКНЕ КУЛЛАНУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

### Сүзлекнең составы

1. Сүзлек, нигездә, төрле тамырдан булган антонимнардан *(ак – кара, бар – юк, җитез – сүлпән, килү – китү, матур – ямьсез, көньяк – төньяк)* тора. Аның составында шулай ук тамырдаш антонимнар *(кызык – кызганыч, оту – оттыру, очып килү – очып китү, сусыл – сусыз, сабырлык – сабырсызлык, сөю – сөелү, хак – нахак, эшчән – эшлексез)* бар.

2. Сүзлектә антонимик (капма-каршы) мәгънәгә ия булган сүзләр төрле сүз төркемнәреннән алынды.

3. Сүзлеккә телебездә актив кулланылышта булган антоним парлар белән рәттән аз санда булса да антоним алынма сүзләр *(пассив – актив, фронт – тыл)* алынды.

### Сүзлекнең төзелеше

1. Сүзлекнең төп һәм күләмле өлешен сүзлек корпусы тәшкил итә.

2. Сүзлек корпусы сүзлек статьяларыннан тора.

3. Сүзлек статьяларының башында торган антоним парлар калын хәрефләр белән билгеләнде һәм җәяләр эчендә нинди сүз төркеменә караган булулары күрсәтелде. Антоним парлар (ишләр) алфавит тәртибендә вертикаль юнәлештә урнаштырыла:

**аз** (рәв.) – **күп** (рәв.)
**азаю** (ф.) – **күбәю** (ф.)
**ахыр** (ис.) – **баш** (ис.)
**зарарлы** (сыйф.) – **файдалы** (сыйф.)
**шатлык** (ис.) – **кайгы** (ис.) һ.б.

4. Антоним парлардан соң аларның мәгънәләре аерым-аерым аңлатыла. Аңлатмалар, нигездә, "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"нә (3 томда, Казан, 1977–1981) таянып бирелә һәм сүзлек статьясының башы итеп урнаштырылган сүзләр тәртибендә килә. Ике сүз аңлатмалары бер-берсеннән нокта һәм сызык белән аерыла. Мәсәлән: **аз (рәв.) – күп (рәв.)**

*Саны ким, микъдары зур түгел. – Шактый санда, байтак санда, саны ягыннан шактый.*

5. Аңлатмалардан соң яңа юлдан антоним парларга төрле чыганаклардан (матур әдәбияттан, халык иҗатыннан, газета-журналлардан, фәнни-публицистик язмалардан) шушы антоним парларның икесе дә булган җөмләләр, кыска текстлар китерелә:

**сафлык (ис.) – бозыклык (ис.)**

*Саф булу сыйфаты, хәле. – Бозык булу хәле.*

Укымак – дөреснең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, **сафлыкның бозыклыкны** җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. *(Г. Тукай)*

6. Иллюстратив материал буларак китерелгән җөмләләрдә, кыска текстларда кыскартылган урыннарга ... (нокталар) билгесе, ә өстәлгән сүзләр җәяләр эченә алынды. Мәсәлән:

**сүнү (ф.) – кабыну (ф.)**

*Яктырып торудан туктау; киеренкелек сүрелү, бетүгә таба бару (иҗтимагый вакыйгалар турында). – Яктырып, елтырап күренә башлау; башлану, көчәю (иҗтимагый вакыйгалар турында).*

Сәгыйтов ... ике дистәгә якын эшчесен заводтан куып чыгарды. Ризасызлыклар моның белән генә **сүнмәде, кабына** барды. *(Ә.Фәйзи)*

**эзләү (ф.) – табу (ф.)**

*Яшерелгән, югалткан яки ачыктан-ачык күренеп торган нәрсәне табарга тырышып, төрле урыннан тикшерү, карау. – Эзләп йөреп кирәк нәрсәне булдыру, шуңа ия булу.*

Хәят матур кашларын җиңел генә күтәренкеләде дә:

– Ах, гафу итегез Николай Иванович, әүвәл менә язам, менә язам дип йөредем дә ... аннан соң Сезнең адресыгыз алмашынган дип ишеттем; яңа адресыгызны Рокыйдән сораган идем, ул, шул вакытта **эзләп** караса да, **табып** бирә алмады, – диде. *(Ф. Әмирхан)*

**алу (ф.) – бирү (ф.)**

*Нинди дә булса нәрсәне кабул итү, аңа ия булу. – Кемгәдер нәрсәдер тапшыру.*

Инде тормыштан яңа байлык, яңа куәт **алырга** түгел, боңарчы (моңа кадәр) алганнарны **бирә** башларга, әкренләп тузарга, сүтелергә вакыт килгән. *(Г. Ибраһимов)*

**йөгерү (ф.) – атлау (ф.)**

*Аякларны тиз-тиз алыштырып, кискен этәрешле адымнар белән бик кызу хәрәкәт итү. – Аяклар белән салмак кына адымнар ясау, адымлау.*

Капканы бикләп алгач, ул (Хөсәен) тагы бер минут чамасы игътибар белән урам якка колак салып торды да **йөгерә-атлый** өйгә кереп китте. *(А. Расих)*

7. Бер үк тамырдан ясалып, төрле сүз төркеменә караган антоним парлар аерым сүзлек статьясы итеп бирелә:

**ач** (сыйф.) – **тук** (сыйф.)
**ачлык** (ис.) – **туклык** (ис.)
**ун** (сыйф.) – **сул** (сыйф.)
**унга** (рәв.) – **сулга** (рәв.)
**яшәрү** (ф – **картаю** (ф.)
**яшь** (сыйф.) – **карт** (сыйф.)
**яшьлек** (ис.) – **картлык** (ис.)

8. Сүзлектә антоним фигыльләрнең, төп юнәлеш формалары белән рәттән, юнәлеш формалары да аерым статьяда бирелә:

**ачу** (ф.) – **ябу** (ф.)
**ачылу** (ф.) – **ябылу** (ф.)

9. Әгәр антоним парларда бер сүз күпмәгънәле булып, шул мәгънәләрнен һәркайсысына (лексик-семантик вариантларына) аерым сүз антоним булса, аларның һәрберсе аерым сүзлек статьясында бирелә һәм гарәп цифрлары ярдәмендә билгеләнә:

**кече**$_1$ (сыйф.) – **зур** (сыйф.)
**кече**$_2$ (сыйф.) – **өлкән** (сыйф.)

Беренче пардагы *кече* сүзе 'кече яшьтәге' мәгънәсендә *зур* сүзе белән антономик мөнәсәбәткә керә: Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казахстандагы **кече** улын һәм Пермь өлкәсендәге **зур** кызын чакырып язуны үтенә башлады. *(Ә. Еники)* Ә икенче пардагы *кече* сүзе 'дәрәҗәсе, зурлыгы, күләме ягыннан зур булмаган' дигән мәгънәсе белән *өлкән* сүзенә антоним булып килә: Дан орденының тулы кавалеры **кече** лейтенант, **өлкән** офицерның үзенә таба килгәнен күргәч, аякка басты һәм гәүдәсен турайтты. *(Г. Әпсәләмов)*

10. Антоним парның бер сыңары икенче бер парның бер сыңарына омоним булырга мөмкин. Бу очрак та сүзлектә үзенең чагылышын таба. Омоним сүзләр рим цифрлары ярдәмендә билгеләнелә:

**баю I** (ф.) – **бөлү** (ф.)

*Байлык җыю; бай була бару. – Мал-мөлкәтеңнән язып нык ярлылану.*

**Байыйсың** килсә – дуңгыз асра, **бөләсең** килсә – айгыр асра. *(Мәкаль)* Бер тиен кергән **баеган**, бер тиен чыккан **бөлгән**. *(Мәкаль)* Ярлы **баеганчы** бер гомер, бай **бөлгәнче** бер гомер. *(Мәкаль)*

Юатучы, кыстап сыйлаучы юк.
**Баесан** да үзең, **бөлсәң** дә... *(Г. Афзал)*

**баю II** (ф.) – **калку** (ф.) //
**баю** (ф.) – **чыгу** (ф.) //

*Бату, офык артына китү. – Күтәрелү, чыгу ( күк җисемнәре турында).*

Яз житсә, төн кыскарыр, көн озаер,
Кояш та иртә **чыгып**, бик тә соң **баер.** *(М.Гафури)*

Ә бәхетле кояш алай түгел: ул **чыга**, күтәрелә, **бата,** югала... *(Г. Ибраһимов)*

11. Сүзлектә антонимнарның синонимнар белән дә мөнәсәбәте күрсәтелә. Бу очракта сүзлек статьясын алфавит буенча беренче торган сүз башлый. Аннан соң // тамгасы куелып, алфавит тәртибендә антонимнарның синонимик парлары (ишләре) бирелә:

**акыллы** (сыйф.) – **ахмак** (сыйф.) //
**акыллы** (сыйф) – **тинтәк** (сыйф.)

*Аңлы, зиһенле кеше. – Акылсыз, юләр, аңгыра.*

**Акыллы** уйлап торганчы, **тинтәк** эшен бетерер *(Мәкаль).* Һөнәрчеләрнең дә **акыллырак** башлары бераз **ахмаграк** башларны яки бер каза сәбәпле бәхетсезлеккә очраган иптәшләрен, коралдан вә эштән аерып, кулларына алырга тырыштылар. *(Г. Тукай)*

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТУЛАР

ис. – исем
рәв. – рәвеш
сыйф. – сыйф
алм. – алмашлык
ф. – фигыль
мод.сүз – модаль сүз
хәб. сүз. – хәбәрлек сүз
ымл. – ымлык
бәйл. – бәйлек
һ.б. – һәм башкалар
функ. – функциясендә
күч. – күчерелмә мәгънәдә

## АЛФАВИТ

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Аа** | **Зз** | **Пп** | **Чч** |
| **Әә** | **Ии** | **Рр** | **Шш** |
| **Бб** | **Йй** | **Сс** | **Щщ** |
| **Вв** | **Кк** | **Тт** | **ъ** |
| **Гг** | **Лл** | **Уу** | **Ыы** |
| **Дд** | **Мм** | **Үү** | **ь** |
| **Ее** | **Нн** | **Фф** | **Ээ** |
| **Ёё** | **ң** | **Хх** | **Юю** |
| **Жж** | **Оо** | **Һһ** | **Яя** |
| **Җҗ** | **Өө** | **Цц** | |